**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.11.2024 **Чирмешән авылы** **№ 379**

**Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау, торакны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торакны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында» 2023 елның 27 декабрендәге 365 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 маддәсенең 4 өлеше, шулай ук Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау, торакны карап тоту өчен түләү күләмен, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 213/пр номерлы боерыгы, «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау, торакны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торакны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын раслау турында» 2023 елның 27 декабрендәге 365 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: 1. «2024 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау, торакны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексын 8 процент күләмендә расларга».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М. Җамалетдинов